**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 сентябрь № 661

г. Казань

Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантларны гамәлгә куярга.

2. Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 сентябрь, 661 нче карары белән расланды

# Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү тәртибен билгели.

2. Грантлар бирү максаты – Татарстан Республикасында югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча рус теле һәм әдәбияты укыту өлкәсендә фәнни һәм фәнни-педагогик хезмәтне мотивацияләүнең нәтиҗәле системасы өчен шартлар тудыру.

3. Грантлар бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) чараларын тормышка ашыруга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт программасы нигезендә, әлеге максатларга бирелә торган акча чикләрендә, һәр ун грантның күләме 100 000 (йөз мең) сум тәшкил итә.

5. Конкурс комиссиясе грант алырга теләүчеләрнең конкурс материалларын карап тикшерә һәм грантлар бирү турында карар кабул итә.

6. Грант алучылар конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

## II. Төп төшенчәләр

7. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Грантлар – субсидияләр рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

грант бирүче – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы – Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан грантлар бирүгә вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы;

Конкурс – Грантлар бирү өчен галимнәрне һәм укытучыларны сайлап алуга бәйле чара;

Конкурста катнашучылар – Татарстан Республикасында рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәр һәм укытучылар;

Комиссия – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 28 февраль, б-389 нчы боерыгы нигезендә төзелгән Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем;

Грант алучылар – Вәкаләтле орган белән грантлар алуга килешү төзегән, Конкурста җиңүчеләр дип танылган галимнәр һәм укытучылар;

галим – «фәннәр кандидаты» һәм (яки) «фәннәр докторы» гыйльми дәрәҗәсе булган югары белем бирә торган мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы хезмәткәре.

## III. Төп максатлар

8. Грантлар бирүнең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасында югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча рус теле һәм әдәбияты укыту өлкәсендә фәнни һәм фәнни-педагогик хезмәтне мотивацияләүнең нәтиҗәле системасы өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасының күпмәдәниятле киңлегендә рус теле һәм әдәбияты укыту өлкәсендә фәнни-педагогик кадрларның һөнәри үсешен мотивацияләү;

филология өлкәсендә милли педагогик кадрлар әзерләүгә таләпләрне арттыруның заманча шартларында фәнни һәм фәнни-педагогик кадрларның сыйфат ягыннан составын яхшырту;

фәнни журналларда фәнни басмалар сыйфатын күтәрү һәм өлешен арттыру;

рус теле һәм әдәбияты укытуның алдынгы тәҗрибәсен куллана торган фәнни-педагогик кадрлар санын арттыру.

## IV. Конкурста катнашу хокукы

9. Конкурста катнашуга Грант алуга документлар тапшырган, һөнәри белем бирү оешмаларында яисә югары белем бирә торган мәгариф оешмаларында рус филологиясе, рус теле һәм әдәбияты укыту теориясе һәм практикасы өлкәсендә белем бирү программалары буенча педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, «фәннәр кандидаты» һәм (яки) «фәннәр докторы» гыйльми дәрәҗәсе булган Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

10. Конкурста әлеге Нигезләмәнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән, пенсия яшенә җитмәгән һәм кимендә 5 ел педагогик эшчәнлек стажы булган затлар катнаша ала.

11. Галимнәр һәм укытучылар конкурс нигезендә сайлап алуда күп дигәндә 4 елга бер тапкыр катнашырга хокуклы.

## V. Конкурсны үткәрү тәртибе

12. Конкурсны үткәрү шартлары һәм вакытлары турындагы мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Сайт) Комиссия тарафыннан Конкурс үткәрү турындагы карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә урнаштырыла.

13. Конкурста катнашу өчен галимнәр һәм укытучылар түбәндәге документларны тапшыра:

а) төп эш урыны буенча оешманың җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән таныкланган әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча анкета-заявка;

б) һөнәри белем турындагы диплом, фәннәр кандидаты һәм (яки) фәннәр докторы дипломы һәм хезмәт кенәгәсе күчермәләре;

в) Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе (барлык битләре);

г) РИНЦ, Scopus, WoS мәгълүматлар базаларында урнаштырыла торган фәнни басмалардагы (беренче бите белән) мәкаләләр күчермәләре һәм монографиянең титул бите, басылып чыгу турындагы мәгълүматлар белән арткы ягы һәм ISBN;

д) әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча фәнни-тикшеренү проекты тасвирламасы;

ж) кертелгән документлар исемлеге.

14. Документлар кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмасында кертелә яки почта аша түбәндәге адреска җибәрелә: 420111, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3 нче йорт; E-mail: Dzhalil.Motygullin@tatar.ru.

15. Документларны кабул итү, Конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат Сайтта урнаштырылган көннән соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

16. Әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү һәм теркәү алар тапшырылган көнне Вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

17. Әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән документлар, аларны тапшыру вакыты тәмамланганнан көннән соң, өч көн эчендә Комиссия тарафыннан карап тикшерелә.

18. Конкурста катнашуга әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган галимнәр һәм укытучылар кертелә.

19. Галимнәрне һәм укытучыларны Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау;

б) документларның әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

в) документларны Конкурска тапшыру вакыты тәмамланганнан соң кертү;

г) галимнәрнең һәм укытучыларның яше һәм педагогик эшчәнлек стажы әлеге Нигезләмәнең 10 нчы пункты таләпләренә туры килмәве;

д) галимнәрнең һәм укытучыларның әлеге Нигезләмәнең 11 нче пункты таләпләрен үтәмәве.

20. Конкурста катнашуга кертелгән галимнәр һәм укытучылар исемлеге һәм Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән галимнәр һәм укытучылар исемлеге Комиссия утырышын үткәргән көннән соң бер эш көне эчендә Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы документларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә үткәрелә.

21. Комиссия утырышының беркетмәсен раслаганнан соң, Конкурста катнашучылар исемлеге, шулай ук Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән галимнәр һәм укытучылар исемлеге эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Сайтка урнаштырыла.

22. Конкурста катнашуга кертелмәгән галимнәргә һәм укытучыларга хәбәр итү беркетмәне раслаган көннән соң өч көн эчендә Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан хәбәрнамә җибәрү юлы белән өстәмә башкарыла.

23. Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән форма буенча билгеләнә.

24. Конкурста катнашучыларның заявкалары, Комиссия утырышын үткәргәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Комиссия әгъзаларына карап тикшерү өчен бирелә. Комиссия әгъзалары, аларга заявкаларны биргән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявкаларны, аларга теркәлгән документларны карап тикшерәләр һәм бәяләү кәгазьләрен Вәкаләтле органга тапшыралар.

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү йомгаклары буенча өч көн эчендә рейтинг төзелә.

25. Конкурста җиңүчеләрне сайлап алу процедурасы Комиссия утырышында рейтинг нәтиҗәләре буенча Комиссия әгъзалары тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы санала.

26. Комиссия утырыш барышында Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый һәм утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән Грантлар бирү турында карар кабул итә.

27. Комиссия утырышының беркетмәсе Комиссия утырышын үткәргән көннән соң бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә, Комиссия рәисе һәм җаваплы секретаре тарафыннан имзалана.

28. Конкурс йомгаклары турындагы мәгълүмат, Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслаган көннән соң, өч көн эчендә Сайтка урнаштырыла.

## VI. Грантлар бирү тәртибе

29. Грантлар агымдагы финанс елының 10 декабренә кадәр әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән фәнни-тикшеренү проектын тормышка ашыру өчен бирелә.

30. Комиссиянең грант бирү турындагы карары Вәкаләтле орган һәм Конкурс-та җиңүче – Грант алучы арасында килешү (алга таба – Килешү) төзү өчен нигез булып тора.

31. Килешү Конкурс йомгаклары турындагы мәгълүмат сайтка урнаштырылган көннән соң 10 көн эчендә төзелә.

32. Килешү формасы Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

33. Килешүдә Грантның күләме, максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында файдаланылмый калган Грантны Грант алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару тәртибе, Гранттан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе, Грант алучының Грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, Грант алучының әлеге Нигезләмә һәм төзелә торган Килешү шартларын үтәү хакындагы нигезләмәне үтәвенә Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә Грант алучының ризалыгы күздә тотыла.

34. Вәкаләтле орган Килешү төзегәннән соң җиде көн эчендә Грантны Грант алучының хисап счетына күчерә.

35. Грант алучы Вәкаләтле орган раслаган форма буенча һәм Килешүдә каралган тәртиптә Гранттан файдалану турындагы хисапны Вәкаләтле органга тапшыра.

## VII. Грант алучының җаваплылыгы

36. Грант алучы Вәкаләтле органга тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

37. Грант Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң утыз көн эчендә Грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

38. Грант түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

а) Грант алучының Грантны бирү шартларын үтәмәве;

б) Гранттан максатка ярашсыз файдалану.

39. Грант алучы әлеге Нигезләмәнең 38 нче пунктында күрсәтелгән сәбәпләр нигезендә Грантны кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле орган бу Нигезләмәнең 37 нче пунктында билгеләнгән вакыт чыкканнан соң җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

40. Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемենә үз ихтыярлары белән кайтарудан баш тартсалар, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә кайтарылырга тиеш.

41. Хисап финанс елында файдаланылмый калган Грант Килешүдә күздә тотылган очракларда хисап финанс елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемենә кире кайтарылырга тиеш. Грант алучы хисап финанс елында файдаланылмый калган Грантны кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле орган унбиш көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемենә кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә

чаралар күрә. Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә үз ихтыярлары белән кайтарудан баш тартсалар, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә кайтарылырга тиеш.

42. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Грантны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә законнар нигезендә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыра.

43. Гранттан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту законнар нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар алу өчен конкурста катнашуга анкета-заявка

1. Ф.И.Ат.ис.:
______________________________________________________________________

Тел.:______________________________

Адрес:____________________________________________________________

E-mail: ___________________________________________________________

2. Эш урыны:
______________________________________________________________________

3. Фәнни-тикшеренү проекты турында мәгълүмат:

Исеме: ______________________________________________________

Юнәлеше: ____________________________________________________

4. Сезнең кайчан да булса дәүләт гранты яки муниципаль грант алганыгыз булдымы? Әгәр булса, елын, проектның исемен һәм грантның суммасын күрсәтегез:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

5. Фәнни-тикшеренү проектының кыскача тасвирламасы (проектның төп бүлекләре эчтәлеген кыскача бәян итү):

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

6. Түләү реквизитлары:

Банкның исеме: ________________________________________________________
адресы:
_____________________________________________________________________________
хисап счеты (р/с): _____________________________________________________

Әлеге анкета белән заявкада китерелгән бөтен мәгълүматның, шулай ук өстәмә материалларның төгәл һәм дөрес булуын белдерәм һәм вәкаләтле органның бездән һәм дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнарыннан китерелгән белешмәләрне тәгаенли торган мәгълүмат соратып алу хокукын раслыйм.

Ф.И.Ат.ис. ________________________________/_____________/
(имза)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы килмим.

Ф.И.Ат.ис. _______________________________/______________/
(имза)

Дата:

Раслыйм

_________________________

(вазыйфа)

_________________________

(Ф.И.Ат.ис.)

______________ (имза)

М.У.

Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар алу өчен конкурста катнашуга фәнни-тикшеренү проекты тасвирламасы

(5 биттән артык түгел)

1. Проектны тормышка ашыра башлаганда хәлнең гомуми тасвирламасы (бер биттән артык түгел):

____________________________________________________________

2. Проектның максатлары һәм бурычлары:

____________________________________________________________

3. Чаралар планы (төп чаралар тасвирламасы, проектны тормышка ашыру этаплары һәм вакытлары):

| Т/с | Тормышка ашыру этабы | Чаралар исеме | Тормышка ашыру вакытлары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектның кирәкле булуын нигезләү:

____________________________________________________________

5. Проект бюджеты (күздә тотылган кертемнәр һәм планлаштырылган чыгымнар сметасы, аны нигезләү):
Чыгымнарның гомуми суммасы (сум):
Грант күләме (сум):

____________________________________________________________ (сум)

| Т/с | Чыгымнар исеме | Таләп ителә торган акча |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| Барлыгы | | |

6. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәләре:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Кушымталар CD, DVD-мәгълүмат саклау җайланмаларында, электрон рәвештә һәм бастырып чыгарылып (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция һ.б.) кертелә.

Ф.И.Ат.ис. ______________________________/______________________/
(имза)

Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары

| Т/с | Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары | Бәяләмә (баллар) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Икътисадый нәтиҗәлелек критерийлары | |
| 1.1. | Проектны тормышка ашыру өчен планлаштырылган чыгымнар һәм аның көтелә торган нәтиҗәләре чагыштырмасы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 1.2. | Проектны тормышка ашыруга чыгымнарның нигезләнгән булуы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 2. | Социаль нәтиҗәлелек критерийлары | |
| 2.1. | Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, аларның проект бурычларына туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 2.2. | Планлаштырылган чараларның проектны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 3. | Өстәмә критерийлар | |
| 3.1. | Проектның актуальлеге, яңалыгы, теоретик һәм гамәли әһәмият- | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | лелеге дәрәҗәсе, тикшеренүнең методологик базасын билгеләү төгәл булу, проектны тормышка ашырудан көтелә торган конкрет нәтиҗәләрне билгеләү | заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 3.2. | Грант алуга заявка бирүченең заявканы тапшыру вакытына эшләнгән фәнни-методик эше, (соңгы 5 елда проект темасы буенча басылып чыккан эшләр саны һәм сыйфаты) | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |
| 3.3 | Тикшеренүнең тулы һәм тирәнтен булуы: проектның эшләнеш дәрәҗәсе, башкару алгоритмы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дан башлап 10 га кадәр |

___